# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге составына керүче Горка авылы

13 ноябрь 2019 ел. № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге составына керүче Горка торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2020 елда Майна авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:
   - урам утларын карап тоту;
   - җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту;
   - янгынга каршы гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру;

3. Әлеге карарны Майна авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы, Горка авылы, Ленин урамы, 2а санлы йорт адресындагы мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Майна авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Гафиятуллин